СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

30.12.2019 с. Верхний Услон № 53-617

Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 9 декабрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар кылды:

1. Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы 2019 елның 30 сентябрендәге 49-561нче номерлы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 пунктындагы 3 абзацындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хисап чоры дәвамында мондый алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 9 декабрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымта формасы буенча керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсыннан файдаланып хәбәр итү юлы белән Татарстан Республикасы Президентына хәбәр итә

(dohod.tatar.ru). Әлеге белдерү, шулай ук белешмәләр (хисап чоры дәвамында «муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган килешүләр башкарылган очракта) хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча бирелә.

1.2. Нигезләмәнең 3 пунктындагы 2 абзацында «даими нигездә» сүзләрен «даими» һәм «даими булмаган нигездә» сүзенә алмаштырырга.

1.3. 2нче кушымтада «Вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатлары» сүзләрен «Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатлары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмә текстын яңа редакциядә расларга (1нче, 2 нче кушымталар).

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,<br>
Югары Ослан муниципаль районы<br>
Башлыгы М.Г. Зиатдинов

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2019 елның 30 декабрендәге 53-617нче номерлы карарына

1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмә

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация Башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация Башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районы Уставы, әлеге Нигезләмә белән муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (алга таба - керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) тапшыру тәртибе билгеләнә.

Әлеге Нигезләмә муниципаль сайлаулар нәтиҗәләре буенча биләү гамәлгә ашырыла торган муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучыларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

2. Әлеге Нигезләмәдә каралган муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар дигәндә, район Советы карары белән расланган исемлек нигезендә, җирле үзидарәнең сайланулы органнары депутатлары, әгъзалары, районның җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затлары аңлашыла.

3. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны федераль законнар нигезендә расланган белешмә формасы буенча даими нигездә биләүче затлар тарафыннан тапшырыла.

Белешмә тутырыла һәм Татарстан Республикасы Президентына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсы аша тапшырыла (dohod.tatar.ru). Муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны даими рәвештә дә, даими нигездә дә биләүче затлар тарафыннан

имзаланган кәгазь чыганактагы күрсәтелгән белешмәнең күчермәсе Советның оештыру бүлегенә җибәрелә һәм законнар нигезендә сакланырга тиеш.

Авыл җирлеге депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы зат күрсәтелгән белешмәләрне депутат булып сайланган, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырган яисә даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны туктаткан көннән алып дүрт ай эчендә, шулай ук белешмәләр (хисап чоры) бирелгән елдан алдагы һәр ел эчендә, «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләрнең хисап чоры дәвамында башкарылган очракта тапшыра. Хисап чоры дәвамында мондый алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 9 декабрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымта формасы буенча керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсыннан файдаланып хәбәр итү юлы белән Татарстан Республикасы Президентына хәбәр итә (dohod.tatar.ru). Әлеге белдерү, шулай ук белешмәләр (хисап чоры дәвамында «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган килешүләр башкарылган очракта) хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча бирелә.

4. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүгә дәгъва кылучы граждан түбәндәгеләрне тапшыра:

1) муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элекке эш урыныңдагы яисә сайланулы вазыйфаны биләү урыныңдагы керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) турында белешмәләр, шулай ук милек хокукындагы мөлкәте турында һәм граждан муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

2) гражданның муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында, шулай ук гражданның муниципаль вазыйфа биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен белешмәләр, шулай ук милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында муниципаль вазыйфаны биләү аена кадәрге айның беренче числосына торышы буенча белешмәләр;

3) хисап чорына (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) оешмаларның устав (җыелма) капиталларында пайлар) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр (әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге өч ел эчендә әлеге гражданның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, бу алыш-бирешләр башкарылган акча алу чыганаклары турында һәм алар хисабына кылынган әлеге килешүләр турында белешмәләр.

5. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче зат ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшыра:

1) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган керемнәре (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук аның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм хисап чоры ахырына торышы буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (31 декабрь);

2) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) алган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) керемнәре турында белешмәләр, шулай ук алар милек хокукында булган мөлкәт турында һәм хисап чоры ахырына аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (31 декабрь);

3) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) турында белешмәләр (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә.

6. Әлеге Нигезләмә нигезендә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр биргән очракта, муниципаль вазыйфа буенча вәкаләтләр бирелмәгән булса (билгеләнмәгән, күрсәтелгән муниципаль вазыйфага сайланган), әлеге белешмәләр аңа язма гаризасы буенча кайтарыла.

7. Муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы граждан даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче зат түбәндәгеләрне ачыклаган очракта, алар тапшырган белешмәләрдә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрдә әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә күрсәтелмәгән яисә нинди дә булса белешмәләр күрсәтелмәгән яисә хаталар тулысынча чагылдырылмаган булса, алар Татарстан Республикасы Президентына әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында төгәлләштерелгән белешмәләр (алга таба - төгәлләштерелгән белешмәләр) тапшырырга хокуклы.

Муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы граждан күрсәтелгән белешмәләр тапшырылган көннән алып бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләр тапшырырга хокуклы.

Муниципаль вазыйфаны биләүче зат әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләр тапшырырга хокуклы.

8. Муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү кануннар нигезендә гамәлгә ашырыла.

9. Белешмәләр тапшырмаган, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затның белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләрен тапшырган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

Объектив сәбәпләр буенча белешмәләрне тапшырмау факты яисә муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмау турында гариза Татарстан Республикасы Президенты билгеләгән тәртиптә каралырга тиеш.

10. Муниципаль вазыйфа биләүче затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының законнарда каралган тәртиптә белешмәләре Югары Ослан муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла, ә бу белешмәләр булмаганда, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында аларның мөрәҗәгатьләре буенча бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла.

11. Муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырыла торган белешмәләр белән эшкә вәкаләт бирелгән Совет аппаратының вазыйфаи заты әлеге белешмәләрне фаш итүдә яисә законнарда каралмаган максатларда файдалануда гаепле, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган белешмәләрне таратуда гаепле буларак законнар нигезендә җаваплы була.

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2019 елның 30 декабрендәге 53-617нче номерлы карарына

2нче кушымта

Вазыйфага билгеләнгәндә гражданнар өчен үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү мәҗбүри булган, һәм шулай ук вазыйфаны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль вазыйфалары исемлеге

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары

Югары Ослан муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе

Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатлары